ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

______________ с. Верхний Услон ______________

1391
«2017 елга Югары Ослан муниципаль районы
буенча юл хәрәкәте куркынычсызлыгын
арттыру» максатчан программасына
үзгәрешләр кертү турында»

Россия Федерациясе Президентының «Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча беренче чираттагы чаралар турында» 2006 елның 02 сентябрендәге 1042 номерлы Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 17 октябрендәге 1707-р номерлы күрсәтмәсе, «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру чаралары турында» 2006 елның 13 декабрендәге 4 номерлы Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе карары, «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча өстәмә чаралар турында» Татарстан Республикасы Президентының 14.11.2007 № ПУ-610 указы, «2006-2012 елларда юл хәрәкәте иминлеген арттыру» федераль максатчан программасын раслау турында» 2006 елның 20 декабрендәге 100 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, «2013 елга Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» республика максатчан программасын раслау турында» 2012 елның 29 ноябрендәге 911 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «2013-2020 елларда юл хәрәкәте иминлеген арттыру» федераль максатчан программасын раслау турында» 03.10.2013 ел, № 864 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 16 ноябрендәге 764 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «2017 елга Югары Ослан муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» максатчан программасына «хокукый аңны күтәрүгә һәм юл хәрәкәтендә катнашучыларның куркыныч тәртибен кисәтүгә юнәлдерелгән чараларны» 3 нче кушымтада Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитетыннан яктылык кайтару элементлары белән тәэмин иткән өчен җаваплы зат «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ алыштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны ТР Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Л.С. Хәкимҗанов

әзерләде һәм бастырды
4 нөсхәдә